Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2018 ел №260

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Уставына үзгәрешләр
проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына тәкъдим ителгән үзгәрешләр проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составын расларга.

3. 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында фикер алышуда гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашу тәртибен расларга.

4. «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында бастырырга:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертүне әзерләүче комиссия составы;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуда гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашу тәртибе;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында №4 кушымта нигезендә халык тыңлаулары үткәрү тәртибе.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча 2019 елның 25 гыйнварында 15.00 сәгатьтә Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының зур утырышлар залында халык тыңлауларын билгеләргә (Әлмәт шәһәре,Ленин урамы, 39 йорт, кабинет 325).

Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районында халык тыңлауларын уздыру турындагы Нигезләмәнең яңа редакциясе нигезендә, комиссиягә Уставка үзгәрешләр кертү проекты һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча фикер алышулар уздыруны йөкләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары А.А. Зиминга йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2018 елның
15 ноябрендәге №260
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты

1) 6 маддәнең 1 өлешендәге 13 пунктын «индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү турында белдерүдә күрсәтелгән хәбәрнамәгә тәңгәл рәвештә (алга таба - планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрларга һәм урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы, рөхсәт ителгән параметрларына туры килү турында хәбәр хаты (алга таба-планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә), җирлек территорияләрендә урнашкан индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объекты җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәү турында хәбәрнамә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү параметрларына туры китерү турында карар кабул итү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру буенча документлар яки капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән бәйле, федераль законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры китерү (алга таба - билгеләнгән таләпләргә туры китерү), Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланылмый торган җир кишәрлеген тартып алу, рөхсәтсез корылмаларны сүтү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклар белән тәңгәл рәвештә» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2) 6.1 маддәнең 1 өлешендәге 12 пунктын «индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү турында белдерүдә күрсәтелгән хәбәрнамәгә тәңгәл рәвештә (алга таба - планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрларга һәм урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы, рөхсәт ителгән параметрларына туры килү турында хәбәрнамә (алга таба-планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә),

җирлек территорияләрендә урнашкан индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объекты җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәү турында хәбәрнамә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү параметрларына туры китерү турында карар кабул итү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру буенча документлар яки капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән бәйле, федераль законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры китерү (алга таба - билгеләнгән таләпләргә туры китерү), Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланылмый торган җир кишәрлеген тартып алу, рөхсәтсез корылмаларны сүтү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклар белән тәңгәл рәвештә» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3) 7 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:
"14) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге №2300-1 Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;

4) 16 маддә:
4.1) 2 бүлек:
а) беренче абзацтагы “Район Башлыгы” сүзләрен, “Район Башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район башкарма комитеты җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга.»;
б) икенче абзацтагы “Район Башлыгы” сүзләреннән соң “контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район башкарма комитеты җитәкчесе” дип өстәргә»;
4.2) 4 өлештәге «, маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгәннәр,» сүзләрен алып ташларга;

5) 26 маддәнең 2 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сәяси партия, профсоюз оешмаларыннан тыш, съездларда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-

төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш;муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешчә катнашу) белән идарә итү яки оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек исеменнән оештыру идарәсенең һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан тәкъдим итү; Федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;» ;

6) 38 маддәнең 2 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән сәяси партия, профсоюз оешмаларыннан тыш, съездларда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш;муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешчә катнашу) белән идарә итү яки оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек исеменнән оештыру идарәсенең һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан тәкъдим итү; Федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;»;

7) 44 маддәдә:

7.1) 1 өлешнең 2 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя бирүне оештыру өчен шартлар тудыра, шулай ук ведомство карамагындагы оешма җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар кабул итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;»;

7.2) 1 өлешнең 11 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге №2300-1 Россия Федерациясе Законы белән каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;

8) 65.1 маддәсендә:

8.1) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы

җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.2) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.3) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.4) 5 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.5) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.6) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.7) 11 өлешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) сүзләрен өстәргә)»;

8.8) 14 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен өстәргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2018 елның
15 ноябрендәге №260
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссия СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәйруллин А.Р. | Әлмәт муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе |
| 2. | Зимин А.А. | Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия секретаре |
| 3. | Салахов И. Р. | депутат, Әлмәт муниципаль районы Советы Президиумы әгъзасы, Түбән Абдул авыл җирлеге вәкиле, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе |
| 4. | Баһманов И.Р. | депутат, Әлмәт муниципаль районы Советы Президиумы әгъзасы, п. г. т. Түбән Мактама вәкиле, законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 5. | Закиров Ш.К. | депутат, Әлмәт муниципаль районы Советы Президиумы әгъзасы, Югары Мактама авыл җирлеге вәкиле, икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 6. | Әфләтунова Р.Е. | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| 7. | Ханнанова Ә.Б. | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хокук идарәсе җитәкчечсе |

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2018 елның
15 ноябрендәге №260
карарына 3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуда гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашу тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы, таләпләре нигезендә эшләнгән, гражданнарның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча фикер алышуда һәм аларның тәкъдимнәрен исәпкә алуда катнашуын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча тәкъдимнәр Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Советына язма рәвештә, кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кертелә:

| №№ п/п | Пункт, пунктча | Проект тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәләр исәпкә алынган проект тексты | Нигезләү | Төзәтмә кертүче автор (Ф.И.О., адрес, телефон, эш, уку урыны, имза) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Тәкъдимнәр, эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында басылганнан соң 20 көн эчендә кабул ителә.

3. Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша (конверт «Устав турында фикер алышу» дип тамгалана ) түбәндәге адрес буенча бирелә: Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт. Гаризалар шулай ук 45-50-32 факсы буенча, халык тыңлаулары үткәрү вакытына 3 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәр һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга гаризалары Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хатлар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссиягә тапшырыла.

5. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләр проектына карата гына кертелә һәм Федераль закон таләпләренә туры килергә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының башка нигезләмәләре белән каршылыкка яисә ризасызлыкка юл куймаска һәм район Уставының нигезләмәләренә төгәл аңлатма бирүне тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге Тәртиптә каралганча, тәртип рәвешен һәм вакытларын бозып кертелгән тәкъдимнәр комиссия карары буенча каралмаска да мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты, шулай ук халык тыңлауларына чыгарылган тәкъдимнәр, Әлмәт муниципаль районында халык тыңлаулары уздыру турында Нигезләмәнең яңа редакциясе нигезендә, халык тыңлауларына чыгарыла.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2018 елның
15 ноябрендәге №260
карарына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында халык тыңлаулары үткәрү тәртибе

1. Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча халык тыңлаулары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 28 маддәсе, Әлмәт муниципаль районы Уставы, Әлмәт муниципаль районында халык тыңлауларын уздыру турындагы Нигезләмәнең яңа редакциясе нигезендә үткәрелә.

2.Район Уставы проекты һәм район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты район Советы тарафыннан каралганчы 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми басылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аның фикер алышуында катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча халык тыңлаулары билгеләү турында район Советы карары да басыла.

Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гражданнарның фикер алышуында катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару таләп ителми, әгәр район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләре, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге норматив хокукый актлар нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта.

3. Район Уставы проекты яки район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча халык тыңлаулары район Уставында билгеләнгән срокларда үткәрелә, әгәр район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләре, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлар нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта.

4. Халык тыңлаулары үткәрү турындагы карар басылып чыккан көннән алып аларны үткәрү көненә кадәр районда яшәүчеләр халык алдында торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр, искәрмәләр һәм төзәтмәләр җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән тәкъдимнәр, искәрмәләр һәм төзәтмәләр халык тыңлауларында катнашучылар игътибарына җиткерелә.

5. Устав проекты яки район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында акт карары проекты буенча халык тыңлаулары үткәрү буенча вәкаләтле орган булып комиссия тора.

6. Халык тыңлауларында район Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, район Советының даими комиссияләре рәисләре рәислек итә ала. Рәислек итүче халык тыңлауларын ача, халык тыңлаулары соравын (сорауларын), тыңлаулар үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә.

7. Рәислек итүче халык тыңлаулары үткәрү инициаторлары, шулай ук халык тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясарга хокукы булган затка сүз бирә.Чыгышларның тәртибе комиссия тарафыннан теркәлгән гаризалар нигезендә билгеләнә.

8. Тыңлауларда катнашучылар, халык тыңлауларында әйтелгән тәкъдимнәргә карата рекомендацияләрен бирергә яки аларга кушылырга хокуклы.

9. Халык тыңлаулары вакытында беркетмә алып барыла. Халык тыңлаулары барышында кергән барлык кисәтүләр һәм тәкъдимнәр халык тыңлаулары секретарена җибәрелә.

10. Беркетмә халык тыңлауларында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм район Советында саклана.

11. Халык тыңлаулары беркетмәсе нигезендә, халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 3 көнлек срокта, халык тыңлаулары нәтиҗәләре төзелә.

12. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм халык тыңлаулары уздырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин